КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1084

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2019 елгы премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен бирү советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Продукциянең һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты, аларның иминлеген тәэмин итү өлкәсендә шактый зур нәтиҗәләргә ирешкән, шулай ук сыйфат белән идарә итүнең югары нәтиҗәле ысулларын керткән өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2018 елгы премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

«Эшлекле камиллек» номинациясендә:

эшчәнлекләрен җитештерү билгеләнешендәге продукция һәм (яки) халык куллануы товарлары җитештерү өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артык булган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «ГКС» фәнни-җитештерү предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Казан шәһәре);

эшчәнлекләрен хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артык булган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (Казан шәһәре), «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (Казан шәһәре);

эшчәнлекләрен җитештерү билгеләнешендәге продукция һәм (яки) халык куллануы товарлары җитештерү өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артмаган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «ТАТПРОМ-ХОЛДИНГ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (Яр Чаллы шәһәре), «Тиссан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (Яр Чаллы шәһәре);

эшчәнлекләрен хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артмаган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «Төбәкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә

техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә (Казан шәһәре), «Уңайлы Йорт» идарә итүче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (Казан шәһәре);

«Җитештерү системалары» номинациясендә:

«Оргхим» җитештерү берләшмәсе акционерлар җәмгыятенә (Түбән Новгород өлкәсе, Урень шәһәре), «ТНГ-Групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (Бөгелмә шәһәре).

2. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен бирү советына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2019 елгы премияләренә дәгъва итү конкурсы лауреатларын һәм дипломантларын бүләкләү тантанасын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин